**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Советы карары**

**2021 елның 21 июне** **№ 28**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советының 2013 елның 19 ноябрендәге 63 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

В «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Советы
КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:

«3.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итәргә мөмкин.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Красновидово авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Красновидово авыл җирлеге Советы рәисе Алешин И.В